ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«СПАССКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ» БУГУЛЬМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«СПАССК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.09.2022г. № 13

**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Спас авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 нче елның 12 маенда кабул ителгән «Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Спас авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеген раслау турында»гы 10 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Законнарга туры китерү максатыннан Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Спас авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Бөгелмә муниципаль районы Спас авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Спас авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә күмү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 12.05.2022 ел, №10 карарына (алга таба – Бөгелмә муниципаль районы Спас авыл җирлеге Башкарма комитетының 12.05.2022 ел, №10 карары) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Бөгелмә муниципаль районы Спас авыл җирлеге Башкарма комитетының 1 пункты карарын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. 2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Спас авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә күмү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 6964 сум 68 тиенгә әлеге карарның 1 һәм 2 нче кушымталары нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.».

1.2. Бөгелмә муниципаль районы Спас авыл җирлеге Башкарма комитетының 12.05.2022 №10 карарының 1 нче кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

1.3. Бөгелмә муниципаль районы Спас авыл җирлеге Башкарма комитетының Спас карарын 2 нче номерлы яңа кушымта белән тулыландырырга.

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Спас авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә һәм бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

.

**Җитәкче** **А.С.Мухалев**

Татарстан Республикасы
Бөгелмә муниципаль районы
«Спас  авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башкарма комитеты
карарының 1 номерлы кушымтасы
13.09.2022 ел, № 13

**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының "Спас  авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә күмү хезмәтенең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе (табутта күмү)**

| *№* | *Хезмәтләрнең исеме* | *Хезмәт күрсәтү бәясе, (сум)* |
|---|---|---|
| 1 | Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2 | Табутны һәм күмү өчен кирәк булган башка әйберләрне бирү һәм җибәрү | 2271,68 |
| 3 | Зиратка үлгән кешенең гәүдәсен (калдыкларын) илтү | 988,00 |
| 4 | Күмү (кабер казу һәм күмү) | 3705,00 |
| БАРЛЫГЫ: | | 6964,68 |

Татарстан Республикасы
Бөгелмә муниципаль районы
«Спас  авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге
башкарма комитеты карарының
2 номерлы кушымтасы
13.09.2022 ел, №13

**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының**
**"Спас  авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә**
**күмү хезмәтенең гарантияле исемлеге нигезендә**
**(төреп күмү) күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе**

| *Хезмәтнең исеме* | *Хезмәт күрсәтү бәясе, сум.* |
|---|---|
| Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| Мәетне (киендерү) төрү | 1348,50 |
| Күмү өчен кирәкле әйберләр белән тәэмин итү һәм җибәрү | 612,44 |
| Зиратка вафат булган кешенең гәүдәсен (калдыкларын) илтү (3,00 сәгать исәбеннән) | 1 560,96 |
| Күмү (кабер казу һәм күмү) | 3442,78 |
| Барлыгы: | 6 964,68 |